СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.04.2026 № 9/1

На №__________ от______________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләрнең җәйге ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру турында

«Тукай муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләрнең җәйге ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүнең һәм эшкә урнаштыруның зур социаль әһәмиятен исәпкә алып, муниципаль район Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.
2. 2026 елның җәйге чорында балалар һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру буенча чаралар планын кушымта нигезендә расларга.
3. Район Башкарма комитетына тәэмин итәргә:

- 2026 елның җәйге чорында «Балкыш» балалар сәламәтләндерү лагере, мәктәп яны сәламәтләндерү лагерьлары, хезмәт һәм ял лагерьлары, профильле лагерьлар эшчәнлеген;
- балаларны яхшы сыйфатлы тукландыруны;
- мәктәп каникуллары чорында балалар һәм яшүсмерләр белән мәдәни-ял итү, физкультура-савыктыру һәм туристлык эше уздыруны;
- район мәгариф учреждениеләрендә балалар һәм яшүсмерләр сәламәтлеге, әлеге учреждениеләрдә санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү мәсьәләләре буенча җәйге сәламәтләндерү кампаниясенә медицина күзәтчелеген.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль сәясәт, инфраструктура үсеше һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе

К.Р. Нәҗмиев